| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

17.06.2022　　　　　　　　　　　　　　　　　№ 751

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе Нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 17 июлендәге 969 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Халык сәнгать һөнәрләре турында» 1999 елның 6 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе турында Нигезләмәне бирелгән яңа редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе Нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 17 июлендәге 969 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.1. пунктының 3 абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:
«- Бөтенроссия Спас ярминкәсен һәм Чаң чыңы фестивален үткәрүгә субсидияләр рәвешендә Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы хисабына керүче Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы чаралары;»

1.2. Нигезләмәнең 5 бүлегендәге 5.3. пунктының ундүртенче абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Ярминкә киңлеген, шул исәптән Ленин мәйданындагы «Осталар ишегалды» саклау 5 көн дәвамында»

1.3. Нигезләмәнең 5 бүлегендәге 5.3. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:
«- Спас ярминкәсе һәм Чаң чыңы фестивале концерт программасында катнашучыларның музыка уен коралларын һәм җиһазларын ярминкә киңлеге территориясенә ташуны гамәлгә ашыра;
- Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы белән килешү нигезендә, ярминкә киңлеген сәнгатьчә бизәүне тәэмин итә;»

1.4. Нигезләмәнең 5 бүлегендәге 5.4. пунктының унберенче абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:
«-Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы балансында булган ярминкә киңлеген чатырлар белән тәэмин итә, аларны монтажлау, демонтажлау өчен идарәче компаниягә ярминкәдә урнаштыру өчен тапшыра»

1.5. Нигезләмәнең 5 бүлегендәге 5.4. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:
« - Ленин мәйданында «Осталар ишегалды» эшен оештыра (30 катнашучы);
-идарәче компания Спас ярминкәсе көннәрендә уздырган концерт программасы репертуарын формалаштыруда катнаша;
-музейлар эшен 21:00 сәгатькә кадәр оештыра, туристик һәм теплоход төркемнәре, шәһәр кунакларын кабул итә.»

1.6. Нигезләмәнең 7 бүлегендәге 7.2., 7.3., 7.4. пунктларын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:
«7.2. Иң яхшы декоратив-гамәли сәнгать осталарын бүләкләү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан «Халык традицияләрен саклап калган өчен» декоратив-гамәли сәнгать өлкәсенә 5748 (биш мең җиде йөз кырык сигез) сум күләмендә акчалата премияләр 1әм 20 диплом каралган, алар Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры боерыгы белән расланган сәнгать Советы турындагы Нигезләмә нигезендә билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы, Алабуга муниципаль районы вәкилләре тарафыннан тапшырыла.
7.3. Ярминкә көннәрендә чыгыш ясаучы иң яхшы фольклор иҗат коллективларын бүләкләү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан «Халык традицияләрен саклап калган өчен» халык сәнгате өлкәсенә 5748 (биш мең җиде йөз кырык сигез) сум күләмендә акчалата премияләр һәм 5 диплом каралган, алар Алабуга

дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры боерыгы белән расланган сәнгать Советы турындагы Нигезләмә нигезендә билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы, Алабуга муниципаль районы вәкилләре тарафыннан тапшырыла.

7.4. Ярминкә көннәрендә үткәрелә торган Бөтенроссия Чаң чыңы фестивалендә һәм 2-чаң кагу концертларында катнашкан мультиинструмент музыка осталарына, фольклор коллективларга, чаң кагучыларга, борынгы музыка коралларында башкаручыларга һәм катнашучыларның башка төр категорияләренә 23000 (егерме өч мең) сум күләмендә - 7 төр номинациягә премияләр каралган, алар Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры боерыгы белән расланган сәнгать Советы турындагы Нигезләмә нигезендә билгеләнә».

1.7. Нигезләмәнең 7 бүлегендәге 7.5. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:
«7.5 Бөтенроссия Спас ярминкәсенең һәм Чаң чыңы фестиваленең ябылу тантанасында гамәлгә куючылар һәм оештыручылар катнашында бүләкләү уздырыла.»

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов